Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XX-3**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 05 марты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, 2021 елның 15 сентябрендә узган гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендщге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кагыйдәләрнең "Ж-1 – индивидуаль торак йортлар төзү зонасы" бүлегендәге таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Параметрлар төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез мөлкәтне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның кыйммәтләре | |
|---|---|---|---|
| | | Аерым торучы бер гаилә өчен йорт | Блоклы йортта бер гаиләгә торак берәмлеге |
| **Җир кишәрлекләренең чик параметрлары** | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 1000 | 1000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Максималь мәйдан | кв.м | 2500 | - |
| Урамның (юл йөрү) фронты буенча минималь киңлеге | м | 12 | 6 |
| **Кишәрлекләр чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары** | | | |
| Кишәрлектәге төзелешенең максималь проценты | % | 40,5 | 55 |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән корылмаларга кадәр минималь калган ара (чигенеш) (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән очракларда) | м | 3 | 3 |
| Кишәрлекнең ян чикләреннән корылмаларга кадәр минималь калган ара (чигенеш) | м | а) 1- брандмауэр диварның булуы мәҗбүри булганда;<br>б) 3 – башка очракларда | а) 0 - күрше блокларга тоташкан очракларда;<br>б) 3 - башка очракларда |
| Кишәрлекнең арт чигеннән корылмаларга кадәр минималь калган ара (чигенеш) (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгәндә) | м | 3 | 3 |
| Төп корылма (мансардны да кертеп) катларының чик саны | кат | 3 | 3 |
| Корылмаларның (төзелмәләрнең) максималь биеклеге | м | 10 | 10 |
| Ярдәмче корылмалар (төзелмәләр) катларының чик саны | кат | 1 | 1 |
| Ярдәмче корылмаларнең (төзелмәләрнең) чик биеклеге (яссы түбә/скат түбә) | м | 3,5/4,5 | 3,5/4,5 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2* | 2* |

2. Кушымта итеп бирелә торган редакциядә шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлек территориясеннән файдалануның аерым шартлары булган картасына үзгәрешләр кертергә һәм расларга:

кадастр номеры 16:34:140101:278 булган 1 062 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген үз эченә алган территориягә карата, ул Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күки авыл җирлеге, Күки авылы, М.Гыйззәтуллин урамы, 30а йорт адресы буенча урнашкан, күп функцияле иҗтимагый-эшлекле төзелеш зонасын билгеләү өлешендә (ОД1).

3. Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күки авылы, Яңа урам, 5 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов